**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы**
**Бэйрэкэ авыл җирлеге Советы**

# К А Р А Р

№ 8 03.10.2021 ел

Санлы финанс активлары һәм санлы хокуклар турында белешмәләр бирү һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бэйрэкэ авыл җирлеге Советының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге «Санлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 778 санлы Указы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы Законы, 2019 елның 17 июлендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бэйрэкэ авыл җирлегенең 6 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Бэйрэкэ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бэйрэкэ авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бэйрэкэ авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бэйрэкэ авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Бэйрэкэ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 30 мартындагы 6 санлы карары белән расланган нигезләмәгә үзгәрешләр кертеп, 8 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) 1) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр, (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлары), санлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүматлар, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең)